**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2021 Балык Бистәсе штп. №284пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны муниципаль заказчылар тарафыннан исәптән чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны муниципаль заказчылар тарафыннан исәптән чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2020 елның 11 февралендәге №91 карарының 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны муниципаль заказчылар тарафыннан исәптән чыгаруны килештерү буенча комиссия төзергә һәм аның составын кушымта итеп бирелә торган редакциядә расларга.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны муниципаль заказчылар тарафыннан исәптән чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 284пи номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны муниципаль заказчылар тарафыннан исәптән чыгару тәртибе турындагы НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны (алга таба- объектлар һәм (яки) чыгымнар) муниципаль заказчылар тарафыннан исәптән чыгару процедурасын билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә объектларны һәм (яки) чыгымнарны исәптән чыгару астында, куллану үзенчәлекләрен тулысынча яки өлешчә югалту, шул исәптән физик яки мораль тузу, йә биләүдән, файдаланудан һәм юк итү, җитешмәү яки урлашу аркасында объектлар һәм (яки) чыгымнарны максатчанан билгеләнеше һәм (яки) күрсәтмә буенча файдалану өчен яраксыз дип тану белән бәйле гамәлләр комплексы аңлашыла.

Муниципаль заказчы астында Татарстан Республикасы муниципаль хакимияте органы яисә Татарстан Республикасы исеменнән эш итүче, балансында әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән объектлар һәм (яисә) чыгымнар булган муниципаль казна учреждениеесе аңлашыла.

3. Объектларны һәм (яки) чыгымнарны исәптән чыгару турында карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты кабул итә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан объектларны һәм (яки) чыгымнарны исәптән чыгару максатчанлыгын, муниципаль заказчылар тарафыннан объектларны һәм (яки) чыгымнарны исәптән чыгаруны карау өчен килештерү комиссиясе төзелә (алга таба - комиссия).

5. Объектлар һәм (яки) чыгымнарны исәптән чыгаруны килештерү турында комиссия тарафыннан карар кабул итү өчен түбәндәге шартларның берсе булу нигез булып тора:

объектның тулы мораль яки физик тузуы, аны төзеп бетерүнең мөмкин булмавы яки икътисади максатка ярашлы булмавы;

табигать бәла-казалары, янгыннар, аварияләр (хокук саклау органнарының, янгын күзәтчелеге органнарының һәм башка вәкаләтле органнарның документаль раславы белән), шулай ук объектны төзеп бетерү өчен яраксыз хәлгә китергән башка

очракларда югалган яки зыян күргән (җимерелгән);

объектның техник торышы норматив-техник документация таләпләренә туры килмәү, әгәр дә аны төзеп бетерү мөмкин булмаса яки максатка ярашсыз булса;

төзелеш алып барылган  проект документациясен документларны карау вакытына норматив таләпләргә яки техник шартларга туры килми торган дип тану, проект документларының гамәлдә булу срогы чыгу;

төзелеш алып барылган  проект документациясен документларны карау вакытына норматив таләпләргә яки техник шартларга туры килми торган дип тану, проект документларының гамәлдә булу срогы чыгу;

проект документациясен эшләүгә, тикшерү эшләренә, проект алды һәм башка эшләргә юнәлтелгән чыгымнарны объектларны төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү) гамәлгә ашырылмаган техник-икътисадый нигезләүләр нигезендә, максатка ярашлы булмаган һәм (яисә) объектны гамәлдәге норматив таләпләргә күчерү турындагы мәсьәләне карау вакытына туры килми дип тану.

6. Муниципаль заказчы, әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны кушып, комиссия рәисе адресына һәр объект һәм (яки) чыгымнар буенча үтенечнамә җибәрә.

7. Юлламаны муниципаль заказчы җибәргән вакытта объект төзелеш подрядының гамәлдәге шартнамәләр (муниципаль контрактлар)  предметы булырга тиеш түгел.

8. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән үтенечнамә белән бергә, муниципаль заказчы комиссиягә түбәндәге документларны һәм мәгълүматны тапшыра:

№ КС-17 формасы буенча объектны төзүне туктатып тору турында акт;

№ КС-18 формасы буенча гамәлгә ашырылмаган төзелеш буенча проект-эзләнү эшләрен туктатып тору турында акт;

башкарылган эшләрне кабул итү турында № КС-2 формасы буенча актлар һәм башкарылган эшләрнең бәясе һәм N КС-3 формасы буенча чыгымнар турында белешмә;

төгәлләнмәгән төзелеш объектының гамәлдәге йөкләмә предметы булмавы турында мәгълүмат;

төзелеп бетмәгән объект фотографияләре;

муниципаль заказчы тарафыннан расланган техник тикшерү акты һәм төзелеп бетмәгән төзелеш объектының техник торышы турында белешмә;

төзелеш өчен җир кишәрлеге бирү турында документлар;

табигый бәла-казалар, янгыннар нәтиҗәсендә һәлакәт, югалту яки зыян салу (җимерелү) турында вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән актларның күчермәләре;

хокук саклау органнарының җинаять эшен кузгату яки туктату турында карары (муниципаль заказчылар балансында булган объектларны урлау яки җитмәүчелек булганда) ;

муниципаль заказчы балансында булган төзелеп бетмәгән төзелеш объекты буенча чыгымнар исемлеге;

чыгымнарны исәптән төшерү  сәбәпләрен нигезләү белән белешмә.

9. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында билгеләнгән срокларда объектны һәм (яки) чыгымнарны исәптән төшерүне килештерү яки сәбәпләрен күрсәтеп, моны кире кагу турында карар кабул итә. Карар комиссия утырышы беркетмәсендә чагыла.

Әгәр әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә, муниципаль заказчылар балансында булган объектны һәм (яки) чыгымнарны исәптән төшерү турында карар кабул итү мөмкин булмаса, комиссия тәмамланмаган төзелеш объектларының яисә проект документларының техник торышына өстәмә рәвештә бәйсез экспертизаны, шулай ук фактта башкарылган эшләр күләменә һәм башкарылган эшләрнең N КС-2 формасы буенча кабул итү турындагы актларга туры килү-килмәвенә өстәмә рәвештә экспертиза соратып алырга хокуклы;

Комиссиянең карар кабул итү вакыты бәйсез экспертиза үткәрү вакытына озайтыла.

10. Тәмамланмаган төзелеш объектын һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән төшерүне килештерүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

объектны төзеп бетерү һәм проект документациясен куллану мөмкинлеге һәм максатка ярашлы булуы;

әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында каралган документларның булмавы.

11. Әлеге Нигезләмәнең 8 пункты нигезендә тапшырылган документлар комиссия утырышларында карала. Комиссия утырышларны комиссия рәисе карары буенча документлар кергән очракта үткәрә. Комиссия утырышы Комиссия составының кимендә өчтән икесен тәшкил иткән кворум булганда тулы хокуклы.

12. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне башкара::

әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында каралган документларны карый;

объект төзелешен тәмамлау максатчанлыгы, аерым узелларны, детальләрне, конструкцияләрне һәм материалларны куллану мөмкинлеге, проект документациясен алга таба куллануның максатка ярашлылыгы мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә;

объектны исәптән төшерү сәбәпләрен һәм (яки) чыгымнарны билгели;

объектны һәм (яисә) чыгымнарны исәптән төшерүне килештерү яки комиссия утырышы беркетмәсенә кул кую юлы белән исәптән төшерүне килештерү турында карар кабул итә.

13. Комиссия карарлары комиссия әгъзаларының гомуми санынан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәдә утырышның датасы, анда катнашучыларның фамилияләре, көн тәртибе, кабул ителгән карарлар һәм ачык тавыш бирү нәтиҗәләре күрсәтелә. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

14. Комиссия тарафыннан тапшырылган документларны карау  һәм муниципаль заказчыга карар белән беркетмәне җибәрү срогы, алар кергән көннән алып, 30 календарь көненнән дә артмаска тиеш.

15. Объектны һәм (яки) чыгымнарны исәптән төшерүне килештерү турында уңай бәяләмә алган очракта, муниципаль заказчы бер ай эчендә объектны һәм (яки) чыгымнарны исәптән чыгару турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе проектын әзерләүне һәм муниципаль заказчылар тарафыннан объектларны һәм (яки) чыгымнарны исәптән чыгару тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә нигезендә әзерләүне гамәлгә ашыра һәм аны билгеләнгән тәртиптә килештерүне тәэмин итә.

16. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителгән объектларны һәм (яки) чыгымнарны исәптән төшерү турында күрсәтмә нигезендә муниципаль заказчы объектны һәм (яки) чыгымнарны әлеге Нигезләмәнең кушымтасына ярашлы рәвештә исәптән төшерү актын рәсмиләштерә һәм бухгалтерлык (бюджет) исәбен алу турында норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә исәптән төшерүне тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны муниципаль заказчылар тарафыннан исәптән чыгару тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта

Форма

## Тәмамланмаган төзелеш объектын һәм (яки) чыгымнарын исәптән чыгару акты

N ______________ "__" _________ 20__ ел

Муниципаль заказчы исеме
_______________________________________________________________________________

Тәмамланмаган төзелеш объекты исеме
_______________________________________________________________________________

Нигезләү
_______________________________________________________________________________

Объектны һәм(яки) чыгымнарны исәптән чыгару сәбәбе
_______________________________________________________________________________

| N п/п | Тәмамланмаган төзелеш объекты турында мәгълүмат | |
|---|---|---|
| 1. | Объект урнашкан урын | |
| 2. | Муниципаль заказчы турында мәгълүмат | |
| 2.1. | Җитәкче Ф.И.О.сы, вазифасы (телефон/факс) | |
| 2.2. | ИНН | |
| 2.3. | Код ОКПО | |
| 2.4. | Код ОКДП (эшчәнлек төре) | |
| 2.5. | Код СООГУ (югарыдагы орган) | |
| 3. | Объектның билгеләнеше | |
| 4. | Җир-хокук документларының булуы | |
| 5. | Проект-смета документларының булуы | |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Төзелеш сроклары | |
| 6.1. | Төзелеш башлау датасы | |
| 6.2. | Төзелешне фактта төгәлләү датасы | |
| 7. | Объектны финанслау суммасы | |
| 8. | Башка чыгымнар | |
| 9. | Төзелешнең башкарылу дәрәҗәсе | |

Муниципаль заказчы җитәкчесе:

_______________ ______________________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Баш бухгалтер:

_______________ ______________________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 284пи номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны муниципаль заказчылар белән килештерү буенча
комиссия составы

| | |
|---|---|
| Исланов Роман Леонидович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Ризаев Дамир Наил улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Токранов Вячеслав Иванович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Хәмидуллин Ирек Мәсгут улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы, комиссия секретаре |

Комиссии әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вафин Фәрид Мансур улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Хәкимуллин Айрат Альберт улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Ногманова Ильсия Мәлик кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Петрова Эльвина Замир кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| | Территориясендә төзелеп бетмәгән төзелеш объекты булган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы вәкиле (килешү буенча) |